КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 23 март г.Казань № 177

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2022 ел, 1 июль, 618 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 3 октябрь, 1217 нче; 2023 ел, 29 декабрь, 1750 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортының 1 бүлегендәге «Татарстан Республикасы дәүләт программасы кураторы» юлының икенче графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы – Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары»;

«Татарстан Республикасының законнар җыелмасын формалаштыру» төбәк проекты паспортының 1 бүлегендәге «Төбәк проекты кураторы» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «Төбәк проекты кураторы | Р.К.Нигъмәтуллин | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары». |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт программалары белән идарә итү системасы турында» 2023 ел, 30 май, 655 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 22 декабрь, 1667 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт программалары белән идарә итү

системасы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктның сигезенче абзацында «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары арасыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Дәүләт программасын гамәлгә ашыру белән идарә итү аның кураторы тарафыннан тәэмин ителә. Куратор итеп Татарстан Республикасы Администрациясе Җитәкчесе Рәисе яки Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары билгеләнә.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген раслау турында» 2023 ел, 22 декабрь, 1667 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

3 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2024 – 2027»;

4 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы – Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин